**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Ошт○рма-Юмья авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**17 август 2022 ел** **№ 21**

**Кукмара муниципаль районы Оштoрма-Юмья авыл җирлегенең Югары Юмья торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Оштoрма-Юмья авыл җирлегенең Югары Юмья авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы Югары Юмья авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Оштoрма-Юмья авыл җирлеге Уставы нигезендә Оштoрма-Юмья авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елның 27 августа 18 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Оштoрма-Юмья авыл җирлегенең Югары Юмья авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы Югары Юмья авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Кукмара муниципаль районы Оштoрма-Юмья авыл җирлегенең Югары Юмья торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы Югары Юмья авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа абзацларны өстәргә:

«-чишмәләрне һәм су белән тәэмин итү системаларын төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);»

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Оштoрма-Юмья авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Оштoрма-Юмья авыл җирлеге башлыгы: С.В. Тимофеев